Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXIX-9**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 19 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы депутаты Р. Р. Зариповның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советы депутаты Р. Р. Зариповның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу сәбәпле, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 маддәсендәге 10.2, 11 өлешләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 29 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 36 маддәсендәге 1 өлешенең 9 пункты, 36 маддәсендәге 3 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы депутаты Зарипов Руслан Рөстәм улының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов